Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Советы

Надеждино авыл җирлеге башлыгы
# КАРАРЫ

24 март, 2026 ел № 7

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Питрәч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә (2017 елның 21 августындагы 66 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 93 номерлы, 2019 елның 20 сентябрендәге 131 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 55 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 62 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1.Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә:

- Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Надеждино авыл җирлеге, Петрово авылы адресы буенча урнашкан 16:33:210301:120 кадастр номерлы, 7769 кв.м мәйданлы җир кишәрлегеннән - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) «Табигатьне танып белү туризмы», «туристик хезмәт күрсәтү», «күңел ачу чаралары» файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты.

2. Гавами тыңлауларны үткәрүне оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 3 апреленнән дә соңга калмыйча тәгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов